ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТУРИЗМУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

01.12.2015 г.Казань № 157

Татарстан Республикасы
Туристлык буенча дәүләт комитетының
2015 елның 17 апрелендәге “Татарстан
Республикасы Туристлык буенча дәүләт
комитеты карамагындагы иҗтимагый
совет турында нигезләмәне раслау
хакында” 44 номерлы боерыгына
үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 18 ноябрендәге “Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый советы турында” 906 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы карамагындагы иҗтимагый совет турындагы үрнәк нигезләмәгә үзгәрешләр кертелү сәбәпле б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының 2015 елның 17 апрелендәге “Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты карамагындагы иҗтимагый совет турында нигезләмәне раслау хакында” 44 номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

боерыкның кереш өлешендәге “(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 15 октябрендәге 856 номерлы, 2013 елның 24 октябрендәге 793 номерлы, 2014 елның 20 сентябрендәге 669 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән)” сүзләрен төшереп калдырырга;

аталган боерык нигезендә расланган Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты карамагындагы иҗтимагый совет турында нигезләмәдә:

1.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1.1. Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты карамагындагы иҗтимагый совет (алга таба – Иҗтимагый совет) Татарстан

Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) карамагындагы, Татарстан Республикасында туристлык өлкәсендә дәүләт сәясәтен формалаштырганда һәм тормышка ашырганда гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен һәм иҗтимагый берләшмәләрнең һәм бүтән дәүләти булмаган коммерциягә карамаган оешмаларның хокукларын тормышка ашыруга бәйле мәсьәләләрне карап тикшерүче, туристлык өлкәсендә дәүләти идарәлек итүне гамәлгә ашыручы, шулай ук шушы нигезләмәдә каралган бүтән төрле вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы киңәшмә органы булып тора.";

2.1 пунктының икенче абзацындагы "Россия Федерациясенең" сүзләрен төшереп калдырырга, "иҗтимагый берләшмәләрнең" сүзләреннән соң текстка "һәм бүтән дәүләти булмаган коммерциягә карамаган оешмаларның" сүзләрен өстәргә;

31. пунктындагы "социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларның" сүзләрен "иҗтимагый берләшмәләрнең, шулай ук дәүләти булмаган коммерциягә карамаган оешмаларның" сүзләренә алмаштырырга;

3.2 - 3.4 пунктларын түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

"3.2. Иҗтимагый совет ирекле катнашу нигезендә 13 кешелек составта төзелә.

3.3. Иҗтимагый совет составына гражданнар, шул исәптән иҗтимагый оешмаларның һәм социаль юнәлешле бүтән коммерциячел булмаган оешмаларның вәкилләре булган гражданнар керә ала. Шул ук вакытта аларның Иҗтимагый совет алдына куелган мәсьәләләр турында фикерләшү өчен кирәкле булган һөнәри сыйфатлары, шул исәптән тиешле белеме, шушы өлкәдәге эш тәҗрибәсе дә исәпкә алына.

Шушы пунктның беренче абзацында күрсәтелгән затлар белән берлектә, Иҗтимагый совет составына Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тарафыннан тәкъдим ителгән, Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санының яртысын тәшкил иткән күләмдәге затлар кертелә.

Иҗтимагый совет составына элек Россия Федерациясе дәүләт вазифаларын, Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясендәге бүтән субъектларның дәүләт вазифаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясендәге бүтән субъектларның дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын, муниципаль вазифаларны һәм муниципаль хезмәт вазифаларын биләгән затлар Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санынан биштән бер өлешеннән артмаган күләмдә кертелә ала.

3.4. Россия Федерациясе дәүләт вазифаларын, Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясендәге бүтән субъектларның дәүләт вазифаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясендәге бүтән субъектларның дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын, муниципаль вазифаларны һәм муниципаль

хезмәт вазифаларын биләүче затлар, суд карары нигезендә хезмәткә сәләтсез дип танылган затлар, үтәлмәгән яки алынмаган суд хөкеме булган затлар, шулай ук 2005 елның 4 апрелендәге “Россия Федерациясенең Иҗтимагый палатасы турында”гы 32-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясенең Иҗтимагый палатасы әгъзалары була алмый торган бүтән затлар Иҗтимагый совет әгъзалары була алмыйлар.”;

3.5 пунктының икенче абзацындагы “карап тикшереләләр” сүзләрен “карап тикшерелә” сүзләренә алмаштырырга;

3.6 пунктын түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

“3.6. Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләре түбәндәге очракларда туктатыла:

үзе тарафыннан Иҗтимагый совет составыннан чыгу турында гариза тапшырылганда;

аның сәламәтлек торышы буенча Иҗтимагый совет эшендә катнашырга сәләтсез булуы, Иҗтимагый совет эшчәнлегеннән читләшүе яки башка сәбәпләр аркасында;

аңа карата чыгарылган гаепләүле суд карары законлы көченә кергәндә;

законлы көченә кергән суд карары нигезендә аны хокукка сәләтсез яки билгесез югалган дип таныганда;

аның тарафыннан этик нормалар тупас бозылганда – Иҗтимагый совет утырышында катнашкан Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санының күпчелек тавыш белән кабул ителгән карар нигезендә;

Россия Федерациясе гражданлыгы беткәндә;

нигезле сәбәпләрсез системалы рәвештә (өч тапкырдан артык) Иҗтимагый совет утырышы эшендә катнашмаганда;

нигезле сәбәпләрсез системалы рәвештә (ике тапкырдан артык) Иҗтимагый совет рәисенең яки рәисе урынбасарының боерыкларын үтәмәгәндә;

аны Россия Федерациясе дәүләт вазифасына, Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте вазифасына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясендәге бүтән субъектларның дәүләт вазифасына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясендәге бүтән субъектларның дәүләт гражданлык хезмәте вазифасына, муниципаль вазифага һәм муниципаль хезмәт вазифасына билгеләгәндә;

аның тарафыннан икеләтелгән гражданлык алынганда.”;

3.8 пунктының дүртенче абзацында “вазифасына кандидат” сүзләрен төшереп калдырырга;

4.1 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

“дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән, персональ белешмәләр турындагы мәгълүматлардан һәм аннан файдалану чикле булган мәгълүматтан

торучы мәгълүматтан файдалану сәбәпле, федераль законнар нигезендә аларга керү чикләнә торган чаралардан тыш, Дәүләт комитеты инициативасы буенча үткәрелә торган барлык чараларда (утырышларда, киңәшмәләрдә, “түгәрәк өстәл”ләрдә һ.б.) катнашырга;”;

5.3 пунктын түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

“5.3. Иҗтимагый совет утырышлары кварталга бер тапкырдан да ким булмаган күләмдә үткәрелә. Иҗтимагый совет утырышларында кабул ителгән карарлар беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Иҗтимагый совет утырышлары шулай ук Дәүләт комитеты инициативасы буенча, Дәүләт комитеты тарафыннан эшләнгән, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан эшләнә торган норматив-хокукый актлар исемлегендә һәм бүтән документларда каралган, шушы башкарма хакимият органнары карамагындагы иҗтимагый советларның утырышларында алдан фикерләшмичә торып кабул ителә алмый торган норматив-хокукый актларның проектларына һәм билгеләнгән тәртиптә Татарстан республикасының Юстиция министрлыгына теркәүгә алу өчен җибәрелә торган Дәүләт комитеты норматив-хокукый актларына Иҗтимагый советның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 29 мартындагы “Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары тарафыннан эшләнә торган, шушы башкарма хакимият органнары карамагындагы иҗтимагый советларның утырышларында алдан фикерләшмичә торып кабул ителә алмый торган норматив-хокукый актларның һәм бүтән документларның составын раслау турында” 214 номерлы карары белән расланган бәяләмәсен бирү максатларында үткәрелә ала.”;

5.4 пунктын түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

“5.4. Әгәр анда Иҗтимагый совет әгъзаларының кимендә өчтән ике өлеше катнашса, Иҗтимагый совет утырышлары хокуклы дип санала. Утырышта шәхсән катнашу мөмкинлеге булмаганда Иҗтимагый совет әгъзасы көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр буенча үз тавышын яки фикерен, бу хакта Иҗтимагый совет рәисенә яки рәисенең урынбасарына яки Иҗтимагый советның җаваплы сәркатибенә алдан хәбәр итеп, язмача, факсимиль яки электрон почта аша Иҗтимагый советның бүтән әгъзасына тапшырырга хокуклы. Үз тавышларын Иҗтимагый советның бүтән әгъзаларына ышанып тапшырган Иҗтимагый совет әгъзалары Иҗтимагый совет утырышында катнашучы әгъзалар санына кушыла.

Шушы Нигезләмәнең 5.3 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән норматив-хокукый актларның проектларын (норматив-хокукый актларны) Иҗтимагый совет тарафыннан карап тикшерү аларны Дәүләт комитеты Иҗтимагый советка тапшырган көннән башлап ун календарь көне дәвамында гамәлгә ашырыла. Шул ук вакытта Иҗтимагый совет бәяләмәләрен бирү максатларында алар буенча тавыш бирү Иҗтимагый советның барлык әгъзалары арасында сораштыру үткәрү

рәвешендә читтән торып тавыш бирү юлы белән, сораштыру нәтиҗәләрен Иҗтимагый совет рәисе тарафыннан, ә ул булмаганда – Иҗтимагый совет рәисенең урынбасары тарафыннан имзалана торган беркетмәгә теркәп гамәлгә ашырыла. Шушы рәвешле тавыш бирү почта, телефон, телетайп, телефон, электрон рәвештә яки кабул итеп алына торган хәбәрләрнең дөреслеген һәм аларның документаль рәвештә раслануын тәэмин итә торган бүтән төрле элемтә ярдәмендә документлар белән алмашу юлы белән дә үткәрелергә мөмкин. Читтән торып тавыш бирүне үткәргән очракта рәис урынбасарына, Иҗтимагый советның барлык әгъзаларына, аны үткәрү датасына кадәр җиде календарь көненнән дә соңга калмыйча, тәкъдим ителә торган көн тәртибе, Иҗтимагый совет бәяләмәсе бирелергә тиешле норматив-хокукый акт проекты (норматив-хокукый акт) җибәрелә. Зарурлык килеп туганда Иҗтимагый совет әгъзалары Дәүләт комитетыннан карап тикшерелә торган норматив-хокукый акт проекты (норматив-хокукый акт) буенча өстәмә материаллар һәм мәгълүмат соратып ала.

Иҗтимагый совет карарлары тавышларның гади күпчелеге белән кабул ителә.”;

5.7 пунктын түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

“5.7. Иҗтимагый совет эшчәнлеге турындагы мәгълүмат “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендә, Дәүләт комитеты сайтындагы Иҗтимагый совет бүлегендә урнаштырыла.”.

Рәис С.Е.Иванов